СОВЕТ СПАССКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
СПАС МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**22.10.2020 ел** **Болгар ш.** **№2-5**

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә бюджет корылышы һәм бюджет процессы турында нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 07 октябрендәге 42-1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (№ 46-3, 30.01.2020, № 48-4, 30.04.2020, № 49-3, 15.06.2020 үзгәрешләр белән)

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 31 июлендәге 263-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә бюджет корылышы һәм бюджет процессы турында нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 07 октябрендәге 42-1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә (№ 46-3, 30.01.2020, № 48-4, 30.04.2020, № 49-3, 15.06.2020 үзгәрешләр белән):

1.1. 10 статьяның 2 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

1.2. 38 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Район бюджеты керемнәренең гомуми күләмен үзгәртүгә китерә торган һәм район Советында район бюджеты турында карар проекты кертелгәннән соң кабул ителгән район Советының норматив хокукый актлары нигезләмәләре агымдагы финанс

елына һәм план чорына бюджетка агымдагы финанс елына һәм план чорына үзгәрешләр кертелгәндә чираттагы финанс елында исәпкә алына».

2. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.spasskiy.tatarstan.ru) һәм хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны финанс-бюджет мәсьәләләре, икътисад һәм җирдән файдалану буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Спас муниципаль районы
башлыгы урынбасары С.И. Тюнев